




# Хәерле көн, укучылар!



# Һади Такташ

1. Һади Такташның туган елы

а) 1905

ә) 1901

б) 1931

2. Һади Такташның туган авылы

а) Кырлай авылы

ә) Сосна авылы

б) Сыркыды авылы

# 3. Һади Такташның әсәре:

а) “Туган авыл”

ә) “Иптәшләр”

б) “ Ата-ана”

4. Һади Такташ кемнән укырга-язарга өйрәнә?

а) Мулладан

ә) Апасыннан

б) Әти-әнисеннән

5. Һади Такташның вафат булган елы:

а)1931
ә)1951
б)1937

# Дөрес җаваплар:

ә
б
ә
б
а

0 хата - ″5″
1 хата - ″4″
2 хата - ″3″
3 хата - ″2″

# Һади Такташ “Мокамай”





# Сүзлек эше

*Җәфа чигү- авырлыклар күрү*
*Һәлакәт – үлем*
*Карак-әйбер урлаучы*
*Баткак – төрле чуалчыклар, буталчыклар*
*Күмәк – бергә*
*Кәсеп –шөгыль*

# Әсәр нәрсәне сурәтләү белән башланып китә?



# Сыркыды ничек сурәтләнә? Шул юлларны табып укыгыз.

Ахры мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында усак яфраклары шаулавын
Алар мәңге минем хыялымда шаулый-шаулый яфрак ярырлар.
Карт имәннәр, калмый минем арттан, кая барсам, озатып баралар...
Бер җирдә юк андый андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары-
Андагыдай шаулый торганнар.

- Бу шигырьдә кемнәр сурәтләнгән?  Алар турындагы юлларны табып укыгыз әле?

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез кара,
Сары чәчлесе ул- мин идем,
Кара чәчле коңгырт кара күзле
Кәкре аяклы дустым, җан кисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем син идең.



# Дусты Мокамай белән икесенә дә уртак сыйфатлар тагын кайсы юлларда чагыла?

Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез дә кара борынлы.
Зурлар кебек, кулны артка куеп,
Йөри идек таптап болынны.
Һәрбер нәрсә безгә яңа иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...
Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме **тал чыбыгы ашадык**,
Әкияттәге ике бала кебек
Күпме "җәфа чигеп" яшәдек...

# Шигырьдә әле кабатланып килә торган дүртьюллыклар бар. Шул юлларны кем табып укый?

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья беләп
Танышып йөргән идек бергәләп...

Ак каенга асылынып менгән кебек
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга таба юл алдым.
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым.
Ә син меналмадың...
Калдың, югалдың...

- Ике дус тормышларын бер үк төрле башлап, төрлечә тәмамлауларын күрсәтү өчен куллана.

Ә Мокамайның  тормышы ничек тәмамлана?



# Ихтыяр көче

Кече яшьтән үк үзеңә-үзең ышанырга;

Төрле авырлыклар алдында сыгылып төшмәскә;

Тыныч күңел белән проблемаларны чишә белергә өйрәнү бик мөһим.

# Өй эше

Әсәрне сәнгатьле итеп укырга.

Сорауларга җавап бирергә.

Һади Такташ дустының гаепсез икәнлеген белсә, әсәрнең эчтәлеге нинди булыр иде? ( прозада яки шигъри юлларда язып килергә)

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!